КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 февраль г.Казань № 156

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 398 нче, 2022 ел, 28 март, 277 нче, 2022 ел, 17 август, 850 нче, 2022 ел, 20 октябрь, 1116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«икенче категориядәге заявка бирүчеләр – Гомумроссия классификаторының B, G, K, L, O, U бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручылардан һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан

Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2023 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 10 февраль, 108 нче карары белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2023 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә кергәннәрдән тыш, Гомумроссия классификаторының B, G, K, L, O, U бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручылардан һәм (яки) инвестиция проектларын тормышка ашыруга кредит шартнамәсе булганнардан тыш, Гомумроссия классификаторының B, G, K, L, O, U бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручылардан тыш, экспортка юнәлтелгән субъектлар, һәм (яки) идарәче компанияләр, һәм (яки) резидентлар булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары;»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

2.2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Физик затлар турында иминият кертемнәре һәм персоналаштырылган белешмәләр, аларны тутыру тәртибе, шулай ук аларны

электрон рәвештә тапшыру форматлары буенча исәп-хисап рәвешләрен раслау турында» 2022 елның 29 сентябрендәге ЕД-7-11/878@ номерлы боерыгы белән расланган «Физик затлар турында персональ белешмәләр» формасы буенча физик затлар турында персоналаштырылган белешмәләрне исәпкә алу урыны буенча салым органына тапшыру бурычын башкара (алга таба - физик затлар турында белешмәләр)»;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мөрәҗәгать итүчеләрнең беренче яисә икенче категориясенә керә.»;

3.1 пунктта:

бишенче абзацта «индивидуаль эшкуарлар өчен» сүзләреннән соң «, юридик затларның, вәкаләтле затларның ышанычнамә буенча законлы вәкилләренең» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «таныклык күчермәсен» сүзләреннән соң «яисә хәбәрнамәне» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка биргән айга кадәрге ай өчен физик затлар турында белешмәләр күчермәсен (электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештә хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турындагы документлар кушымтасы белән тапшырыла);»;

унбишенче абзацта «физик зат» сүзләреннән соң «, индивидуаль эшкуар, юридик затның законлы вәкиле, ышанычнамә буенча вәкаләтле зат» сүзләрен өстәргә;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органының заявка бирү датасына кадәр кимендә биш көннән дә иртәрәк булмаган вакытта Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә бирү форматларын раслау хакында» 2021 елның 6 августындагы ЕД-7-19/728@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплары торышы турында белешмә кәгазен.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Вәкаләтле оешма «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә түбәндәге белешмәләрне һәм документларны ала:

заявка биргән датага торышы буенча бирелгән Юридик затларның (индивидуаль эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү урнаштырыла торган айга кадәрге айның 20 нче көненә карата салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булу-булмавын раслый торган белешмәләр;

заявка бирү датасына бирелгән торышы буенча Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан өземтә.»;

3.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле инвестиция проектларына туры килә торган 2023 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1464 нче карары белән расланган 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2023 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә керә торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларында катнашырга рөхсәт бирелгән икенче категориядәге заявка бирүчеләр әлеге Тәртипнең 3.1 нче пунктында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә вәкаләтле органның тиешле боерыгы белән расланган сатып алуларны, товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне башкарганда тәэмин итүчеләр (башкаручылар, подрядчылар) буларак үстерүне стимуллаштыру максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка ярдәм күрсәтү буенча төбәк квалификация комиссиясе утырышы беркетмәсеннән өземтә тапшырырга хокуклы.»;

4.1 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның өченче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәсе» сүзләрен «субсидия бирү тәгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга»;

5.4 пунктта «иминләштерелгән затлар турында белешмәләрнең күчермәләре» сүзләрен «физик затлар турында белешмәләрнең күчермәләре» сүзләренә алмаштырырга;

5.5 пунктта «иминләштерелгән затлар турында белешмәләр күчермәләре (электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештә хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турындагы документлар кушымтасы белән Пенсия фонды органнары тамгасы белән тапшырыла)» сүзләрен «физик затлар турында белешмәләр күчермәләре (электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештә хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турындагы документлар кушымтасы белән тапшырыла)» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 5 нче кушымтада:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процenttан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре

капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль салым хезмәтенең «Физик затлар турында иминият кертемнәре һәм персоналаштырылган белешмәләр, аларны тутыру тәртибе, шулай ук аларны электрон рәвештә тапшыру форматлары буенча исәп-хисап рәвешләрен раслау турында» 2022 елның 29 сентябрендәге ЕД-7-11/878@ номерлы боерыгы белән расланган «Физик затлар турында персональ белешмәләр» формасы буенча физик затлар турында персоналаштырылган белешмәләрне исәпкә алу урыны буенча салым органына тапшыру бурычын башкара»;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мөрәҗәгать итүчеләрнең беренче яисә икенче категориясенә керә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин